КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 30 июнь г.Казань № 771

2023 – 2030 елларга Татарстан Республикасында хәерчелек чигеннән түбәнрәк керемле халык өлешен киметү буенча төбәк программасын раслау турында

Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы Указын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 1 октябрендәге б-2765 номерлы боерыгын һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының хәерчелек чигеннән түбәнрәк керемле халык өлешен киметүнең төбәк программаларын эшләү буенча методик тәкъдимнамәләрне раслау һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2020 елның 11 июнендәге 326 номерлы боерыгы үз көчен югалткан дип тану турында» 2023 елның 3 мартындагы 128 номерлы боерыгын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2023 – 2030 елларга Татарстан Республикасында хәерчелек чигеннән түбәнрәк керемле халык өлешен киметү буенча төбәк программасын (алга таба – Программа) расларга.

2. Программаны гамәлгә ашыру өчен җаваплы республика башкарма хакимият органнарына (алга таба – җаваплы башкаручылар):

Программаның чараларын чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган акча чикләрендә үтәүне һәм Программага 2 нче кушымтада каралган Татарстан Республикасының төп макроикътисади күрсәткечләренә ирешүне тәэмин итәргә;

квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 15енә кадәр, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау

министрлыгына Программага теркәлгән 5 нче һәм 6 нчы кушымталардагы формалар буенча Программаның үтәлеше турында мәгълүмат кертүне.

3. Программаны гамәлгә ашыру өчен җаваплы федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, бүтән органнарга һәм оешмаларга түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Программаны гамәлгә ашыруда катнашуны;

квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 15енә кадәр, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Программага теркәлгән 5 нче һәм 6 нчы кушымталардагы формалар буенча Программаның үтәлеше турында мәгълүмат кертүне.

4. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына җаваплы башкаручылар тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматны җыюны гамәлгә ашырырга һәм гомумиләштерелгән мәгълүматны квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 20сенә кадәр Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына кертергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин